Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

19 октябрь, 2020 ел № 1

Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәч авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 141 номерлы Кибәч авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Кибәч авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Җыенны 2020 елның 4 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзәк урамы, 1А адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда Кибәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, көндезге уку формасы студентларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кибәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов